КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июль г.Казань № 710

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 февраль, 76 нчы карары белән расланган Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 февраль, 76 нчы карары белән расланган Тарихи җирлек территориясен тотрыклы үстерү концепциясен әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан

юридик затларга субсидия бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

3.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, шулай ук субсидия алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Субсидия алучы бирелә торган хисап мәгълүматының дөрес булмавы һәм субсидиянең нәтиҗәле файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.»;

V бүлекнең исемендә «, максатларының» сүзен төшереп калдырырга;

5.2 һәм 5.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалык бирә.

5.3. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары тикшерүне Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашыра.»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Бирелә торган субсидияләрне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Тәртипнең 2.3 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин